| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**05.02.2018 ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 235** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре һәм муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне арттыру турында» 2014 елның 18 октябрендәге 768 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1000 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2014 елның 20 гыйнварындагы 45 номерлы Башкарма комитеты карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елның 1 гыйнварыннан вазыйфаи окладка , стимуллаштыручы характердагы түләүләргә (башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрдән һәм премия түләүләреннән тыш) һәм авыл җирлегендә эшләгән өчен түләүләргә өстәмә 14 процент күләмендә билгеләргә, аларның хезмәт хакы шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары белән җайга салына:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы 678 номерлы;

«Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2012 елның 10 декабрендәге 1072 номерлы.

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2014 елның 20

гыйнварындагы 45 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 09 ноябрендәге 2323 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин